



# Бербөтенлек

**Сираҗиева Сәгыйдә Фәүзи кызы Татарстанның Мөслим районы Метрәй авылында 1959 елның 25 июлендә туган. Авыл мәктәбендә, аннан Лениногорск рәсем-музыка педагогия көллиятендә белем ала. 1990 елдан Чаллының 1 нче рәсем мәктәбендә укыта. 2005 елдан Россиянең һәм Татарстанның Рәссамнар берлеге әгъзасы. Халыкара, республикакүләм һәм региональ күргәзмәләрдә һәрдаим катнаша. 2010 елдан рәссамнарның этник «Тамга» төркеме әгъзасы. Чаллыда яши.**

## Мөслим кызы Сәгыйдә

*Мөслим белән Метрәй юлы,*
*Күпер буе, Ык суы,*
*Кайтам әле авылыма,*
*Күңелем нечкә, тулы.*

(«Хатирә»)

Бу дөньяда хәсрәтләләр шулкадәр күп. Аһ-зарларсыз, борчуларсыз затны табармын димә. Безгә бит һәрвакыт нидер җитми: байлык, вакыт, мәхәббәт... Алай да, борчу-мәшәкатьләр чоңгылына ияреп зыр әйләнгән дөньядан зар-интизар яудырмый гына, һәр көнгә, һәр мөмкинлеккә шөкер итеп яшәүче бер кешене беләм мин.

«Минем туган җиремнән һәм торган җиремнән дә ямьлерәк урын юк бу дөньяда, – ди Сәгыйдә ханым елмаеп. – Мин шушы җиргә тамырларым белән береккәнмен». Туган ил, туган җир кадерен һәм шул илдә үз кадерен аңлый торган шәхес сүзләре бу. Аларның ихласлыгын күңел күзе белән күреп,

ышанып, сокланып тыңлап утырам. Җыйнак, җылы һәм остаханәләрдә генә була торган мәгърур бер тынычлык белән өретелгән бүлмәнең аръягында – урамда кар ява. Эреле-ваклы кар бөртекләре, дөньяви мәшәкатьләр кеби, бөтереләләр, уйныйлар, пыр тузалар. Ә мин менә рәссам хозурында. Аның ипле генә сөйләмен, рәсем-картиналарын күңелемә сеңдереп утыра бирәм. Җанга уелып калсын әле алар – чын бизәкләр ич!

Мөслим районы Метрәй авылында, ямьле Ык буйларында туып-үскән ул. Электрик Фәүзи абзыйның кадерле икенче кызы булып дөньяга килгән. Сәгыйдә дип исем биргәннәр кызчыкка. Авыл гаиләсендә бала-чага хезмәт белән тәрбияләнеп үсә. Алар өендә дә иркенләп рәсем ясап утырган кеше булмаган, билгеле. Алай да, әткәсе ягыннан кул эше осталары, һөнәрчеләр нәселеннән бит ул. Тоемлау сәләте, көч һәм күңел сизгерлеге дә бармакларга тумыштан салынгандыр. Ә болай, Сәгыйдә үзе математика, физика фәннәрен аеруча ярата, мәктәптә яхшы укый. Исәбе – унберенчене тәмамлап, югары уку йортына керү. Һәм очучы булырга хыяллана ул. (Гаҗәп хәл, иҗат әһелләреннән байтагының балачак хыялы!)

Әмма язмыш дигән кодрәтле көч бар бит әле. Сигезенчене бетергән җәйдә сыйныфташы Зөлфиянең әнисе беркөнне кызга гозер белән килә. (Зөлфия Мөхәммәтдинова – рәссам, шамаилләр ясау остасы). Лениногорскидагы рәсем-музыка педагогия көллиятенә укырга кереп карагыз әле, диюе икән. Кызына иптәш-юлдаш барлаган авылдаш апаның үтенечен аяк астына салып ташламый Сәгыйдә. Кызлар Лениногорск каласына юл ала. Һәм, ни хикмәт, икесе дә укырга кереп кайталар. Аллаһы Тәгаләнең Сәгыйдәне үзенә насыйп очышлар юлына илтер сукмакка бастырып куюы шушы булгандыр.

Еллар үткәч, бу сукмак Чаллыга китерә. Ир хатыны, ике бала әнкәсе, кара толымлы мөлаем ханым булып килә ул бирегә. Һәм гомерлеккә кала. Яңа шәһәр – башлангычлар, мөмкинлекләр төбәге яшь гаиләне үзенә тарта. Сәгыйдә баштагы чорда бизәүче булып эшли. 1990 елдан шәһәрнең 1 нче рәсем мәктәбенә мөгаллим булып урнаша. Биредә инде танылган рәссам Мәдьяр Шәрипов гөр килеп эш оештырган. Сәләтле яшьләр күп, һәм аларга талантлы остазлар бик кирәк чак. Шул ук елны әлеге уку йортына Рият Мөхәммәтдинов та эшкә килә. Акрынлап, иҗади мохит туа. Иҗат офыкларын ачу, үз күңеленә үзе багу өчен бик тә кирәкле тирәлек була ул Сәгыйдәгә. Рәссам язмышы шушы мәктәптә башлана.

## Сурәтләрдән хәтер бага

*Җан бишеге – җиде күк каты.*
*Йөрәгемә кинәт ут капты,*
*Шул чагында галәм киңлеге*
*Миңа алтын капкасын ачты...*

(«Җан бишеге»)

«Рәсем ясау кешене кирәкмәгән уйлардан ерак тота. Картинаны эшли башладыңмы, шуны гына уйлыйсың, шуның белән яшисең. Кайсы рәсем еллар буе аңда, күңел төпкелендә йөри, кайберсе бик тиз генә туа һәм ясала да». Әнә шулай гади генә аңлата ул. Юкса, рәссам Сәгыйдә Сира-



Дала. 90х60, 2007



Алтын Урда сериясе. Тайдула. 90х80, киндер, майлы буяу, 2019

жиеваның тормыш офыкларын кара болыт каплаган кайгылы көннәре дә шактый була бит. Газиз әнкәсе, сөеклесе – тормыш юлдашы һәм сеңлесе белән энесе бер-бер артлы дөнья куялар. Бер хәсрәттән аңга килә алмаганда, кайгы өстенә кайгы кусәге китереп суга тора. Югалту арты, югалту. Әмма шушы югалтулар аша ул гүя үз иҗат юлын таба, дисәм ялгышмамдыр. Бәлки, хәсрәт тулы дөньялыктан матурлыкка – якты, җылы төсләр илөнә «качуы» булгандыр.

Сәгыйдә ханым, чагыштырмача, соңрак, тормышның ачы-төчесен татып, күңел багажы туплап, фәкать 38 яшендә генә иҗат эшенә, композицияләр ясауга ныклап тотына. Әлбәттә, рәсем мәктәбендә мөгаллим буларак, ул һәрдаим иҗат итүдә. Мәктәпнең үз күргәзмәләр залы бар, анда гел яңа эшләр кирәк, ләбаса.

Күңел моңнарын сурәтләргә, төсләргә, рәсемнәргә төшерә башлаган Сәгыйдә ханымга үз мохите – талантлы рәссамнар тупланган мәктәп зур терәк була. Киңәш-табыш, фикердәшлек – болар барысы да аның кылкаләмен һәм үз-үзенә ышанычын ныгыта. Сәгыйдә Сираҗиева иҗатта күбрәк графиканы үз итә. Аның «Күңелем Тукай белән сөйләшә», «Бөек Болгар», «Сөембикә», «Төрки дөнья», «Татар җырлары», «Тормыш фәлсәфәсе» серияләре – график алым белән язылган күренекле әсәрләре.

Табигать, галәми көчләр һәм кешенең бербөтенлеге – «Бөек дала» (2008) сериясендәге картиналар әнә шушы фикергә инандыра. Дөнья тоташ хәрәкәттә, агымда, әйләнүдә. Рәсемнәрдә тоемланган бу туктаусыз хәрәкәт борынгы бабаларыбызның күчмә тормышы белән бик тә аваздаш, хәтта ки бербөтен агым буларак аңлашыла. Хәрәкәттә булганда (үз хак юлыңнан атлаганда гына!), җир дә, су һәм һава да сиңа юлдаш һәм терәктәш булачак. Әнә ич, кояш та – гүя арба тәгәрмәче, җил дә һәрвакыт киң кочагын җәйгән. Табигать үзе тынгысыз бер гаярь көч булып алга әйди. Әлеге картиналардан ирек, хөрлек бөркелә. Саф сулышлы дала җиле йөзгә бәргән төсле, җан рәхәт бер дулкынга ияртә...

Шушы тарихи кайтавыздан, мәҗүси халәттән аерыласы килмичә, «Төркиләр дөньясы» («Мир тюрков»,



*Татарстан легендалары сериясе. Алтынчәч турында истәлек. 70х90, киндер, майлы буяу*



*Татарстан легендалары сериясе. Рабига. 70х90, киндер, майлы буяу, 2016*

2014) сериясендәге рәсемнәрне күзлим. Оланнарына мәрхәмәт белән багучы Умай Ана, казан астындагы учакны саклаучы хатыннар, ат өстендәге кыз, хәерхаклы әнкә – болар барысы да тормыштагы хатын-кыз башлангычын, аның миссиясен аңлата торган образлар. Гомумән, Сәгыйдә Сираҗиева үз иҗатында хатын-кыз образларына зур игътибар бирә. Төрки дөньяның мәшһүр хатыннарына багышланган әсәрләре дә шактый. Әйтик, Сөембикә-ханбикә хакындагы серия картиналары гүя хатын-кыз күңеле генә тоя алган нечкә җеп-хисләрдән тукылган. Сызланулар белән сызылган рәсемнәр бу. Халык күңеленә мәңгелек сагыш булып төенләнгән Сөембикә-ханбикә тарихы аклы-каралы картиналар аша кабат яңартыла. Ул – ил-җирнең калканлы сакчысы да, хәсрәтле бала анасы да, манарасын (халкын) гасырлар буе рухы белән терәтеп торучы тарихи терәк тә, кулларына очар кошлар тоткан (ә үзенең исә каекларда дошман хозурына – читлеккә китеп барышы) хөрлек символы да...

Сәгыйдә Сираҗиева иҗаты дигәндә, тарихи хәтергә чакыручы рәсемнәрне – борынгы төрки символларны, җир, су, һава һәм фани тормыш бирлеген күз уңында тотарга кирәк. Дала җиле китергән хәбәрләргә тын гына күнеп утыручы балбаллар, ак бүре, арба тәгәрмәче булып вакыт агышы буйлап тәгәрәүче кояш, татар орнаментлары һәм башкалар – барчасы да серлелек һәм тирән мәгънә салынган әсәрләр. Ул сер пәрдәләре ачкан саен ачыла, тәүге карашка күзгә ташланмаган мәгънә төсмерләре куера һәм... үзең белән – үз каның, үз тарихың белән күзгә-күз каласың.

«Күңелегезгә каян килә болар?» – дип, самими гаҗәпләнеп сорау бирәм. Гадәтенчә, җылы елмая да, бик гади нәрсәләр турында сөйләгән кебек кенә аңлатып бирә: татар авылында, үз халкының бөтен хиссиятен, көй-моңнарын, кыйммәтләрен, төс-бизәкләрен аңына, җанына сеңдереп үскән бит ул. Халык тарихы, борынгы бер кайтаваз булып, канына күчкән. Әсәрләремә шул кайтаваз төсләрен бушатып, җаныма ял алам, ди. Ә үз тормышы хәлләрен: кайгысын да, шатлыгын да иҗатында сурәтләргә яратмый

рәссам. «Йөрәк бар кешедә дә авырта инде ул. Әмма хәсрәт-сагышларымны рәсемгә салып, кешеләргә тәкъдим итәргә хакым юк минем. Үз кайгылы халәтеңне кеше күңеленә күчерү ник кирәк? Иҗат якты, күңелне куандыра торган булырга тиеш», – дип исәпли. Һәм шулай эшли дә. Күрче, мәрхүм энесе белән сеңлесенә багышланган сирәк картиналарында никадәр яктылык, нур. Хәтта ки иҗатындагы иң төсле әсәре, бәлки, нәкъ шушыдыр да! «Имәнәй тау» дип атала ул. Якын кешеләре, әйтерсең, туган авылының шушы биек тавы башыннан күккә ашканнар. Дөнья хозур, дөньялык та, авыл урамындагы йортлар кебек, дөрес тәртиптә, көн кояшлы, җылы. Әйтерсең, бу сурәтләр якыннарын югалту сагышыннан ачыргаланган мәлләрдә язылмаган да, күңел сызмаган. Җанга аеруча якын хәлләрне, кешеләрне шулай туган якта, җанга газиз җирдә сурәтләү үзе үк ихласлык һәм туган туфракка мәхәббәт турында сөйләмиме соң?

Янә бер кызыклы әсәре – «Хәтер» триптихы (2005) исә шомлы, сагайта торган иҗат үрнәге. Бөек Ватан сугышына, гомумән, сугышларга багышланган бу картиналар канлы-кызыл төсләр өстенлеге белән үк сискәндереп җибәрә. Сугышны тәннән җанны аеручы үлем фабрикасы буларак тәкъдим итә рәссам. Канлы кызыл торбалар – сугыш юлы. Завод-фабрика торбаларыннан чыккан төтен кебек аппакъ җаннар күккә аша. Бу куркыныч торбалар җете-кызыл төстәге җиңү байраклары фонында сурәтләнә. Байраклар әле яңа гына яшь солдатларның кулында булган саклану калканнарына кадалган. Ул калканнар – өем-өем. Аларның инде кирәге юк, сакланасы гомерләр сакланмаган. Җаннар, ак күгәрчен булып, күккә күтәрелә. Сугышның мәгънәсезлеге һәм, нинди генә купшы сүзләргә төреп сөйләсәң дә, асылда, барыбер фәкать үлем чыганагы булуы турында искәртә әлеге әсәр. Әнкәйләр карашы белән, аналар күңеле аша язылган триптих бу. Каберләр өстенә иелгән хатын-кыз образындагы җиде фәрештә дә бу фикерне куәтли. Әнкәйләрнең сугышка нәфрәте, рәнҗеше буларак та кабул ителә.

Рәссам иҗатындагы миллилек, рух һәм тарихилык читтә яшәүче милләттәшләребез күңеленә дә хуш килә. Интернет челтәре аша Сәгыйдә Сиражиеваның әсәрләре белән Румыниядә гомер кичерүче кырым татары Мурат Танер кызыксына. Шагыйрь милләттәшебез Сәгыйдә ханымның әсәрләрен әдәби җыентыклар, журналлар тышлыгында бастырып чыгара. Милләтпәрвәр Мурат ага халкыбызның күңел бизәкләрен нәкъ менә Сәгыйдә Сиражиева иҗатында күрә.

## Киләчәккә таба

*Халкым дибез...*
*Халык рухы сиңа –*
*Чал гасырдан иңгән*
*Моңлы көй.*
*Йөрәгеңдә*
*Сәнгать фәрештәсе,*
*Шигъри җанда –*
*Тирән якты уй.*

(«Шагыйрь-рәссамга»)

«Ана йөрәге бервакытта да тыныч булмый. Әни булу – гомерлек бәхет һәм тынгысызлык ул». Ике бала әнкәсе һәм өч оныкэбкәсе булган Сәгыйдә ханым сүзләре бу. Ике кызы – ике

канаты, ә оныклары турында сөйләгәндә, күзләреннән ихлас нур агыла төсле. Хатын-кызны чынлап бәхетле итә торган газиз хис – ана мәхәббәте. Бу бәхете рәссам ханымның иҗатында да ярылып ята. Кайсы гына әсәрен алма, хатын-кыз образы, тәү нәүбәттә, ана буларак тасвирлана.

«Бәхет» (2013) сериясендәге картиналарда, әйтик, бишектәге сабый бала – бәхетнең үзе булып тәгаенләнә. Ул – яшәүнең үзәге, бар дөнья, йортлар, манаралар, бар табигать аңа баш игән, аны саклый. Киләчәк кешесенең ике кулында ике кош – пар фәрештә. Алдында – битләре ачылган китап. Китап символы Коръән буларак та, ата-баба тарихы, теле, язма мәдәнияте буларак та аңлашыла. Сабый янәшәсендә анасы һәм әбкәсе (нәкъ Тукай шигырендәгечә!). Яшь әни аналарда гына була торган тынгысызлык, борчылу белән оланына таба талпынган халәттә бирелә. (Ана күңеле балада шул!) Әби-карчык исә – олпат, сабыр, ипле. Әсәрдәге бала образы энисе һәм әбекәе өчен генә түгел, кешелек, милләт өчен дә бәхет буларак кабул ителә.

Сәгыйдә ханым – бик бәхетле кеше. Ул тормышта гына түгел, иҗатта да дәвамчылары булачагын белә. Дөресрәге, ул иҗатташ дәвамчыларын үзе тәрбияли. (Кызы Алсу Шихова да – рәссам, шәхси күргәзмәләр оештырган автор). Өч дистә ел буе рәсем мәктәбендә сабыйларга кылкаләм серләрен төшендергән мөгаллимәнең киләчәк буын сынлы сәнгатенә үз өлешен, үз эзләрен салдым, дип әйтерлеге бар. Хезмәтенең ике канаты – иҗаты һәм остазлыгы. Һәр икесенә дә күңел биреп, тугъры калып һәм аларны бербөтен итеп башкара ул.

Укучылары турында сорашам. Һәрберсе хакында бик кадерләп, олылап сөйли. Балаларны аңлый белергә кирәк, шәхес итеп карарга кирәк, ди. Үзе аеруча өмет баглаган укучыларының иҗади киләчәге өчен борчыла. Иң ачынганы – республикабызда милли рәсем сәнгате буенча белем бирә торган югары уку йорты булмау. Юкса, безнең сынлы сәнгатебез башкаларныкыннан үзгә ич, аның үз традицияләре, үз карашлары бар. Менә шушы кыйммәтләрне киләчәк буын рәссамнарына төшендерергә иде, алар чит халык сәнгате үрнәгендә белем алып, иҗатта милли рухны җуймасыннар иде, дип хафалана мөгаллимә.

Бүгенге чор балалары бөтенләй башка, аларга, гомумән, үзгә якын килү кирәк, дип исәпли остаз. Моның өчен заманадан калышмау мөһимлеге хакында да искәртеп үтә. Шәхси сайтын булдырган, үз иҗат үрнәкләре белән берләттән, хөрмәтләп, укучыларының эшләрен дә урнаштырган. Нәкъ шушы сайт аша рәссам ханымның шигырьләре белән таныштым мин. (Кайберләреннән өзекләрне язмамда кулландым да). Шигырьләре дә үзе һәм сынлы сәнгать әсәрләре төсле якты, нурлы һәм җанга ял бирә торган. Зыр әйләнгән җир шарын гүя бер мизгелгә туктатып, үзенә, тарихыңа, бүгенгенә күз салырга мөмкинлек бирә торган иҗат ул – Сәгыйдә Сираҗиева иҗаты. Аның картиналарына тормыш, вакыт һәм адәми зат бербөтенлеге, шушы бөтенлекнең кодрәте, матурлыгы язылган.

**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА.**